ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 109 от «14» 09 2018 г.

Район башлыгының
2016 елның 10 ноябрендә кабул ителгән
112 нче санлы карарына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү хакында

Мамадыш районы прокуратурасының 2018 ел, 22 август, 2057в-2018 нче санлы протесты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында” 2018 ел, 18 июль, 840 нчы санлы карары нигезендә к а р а р б и р ә м :

1.Муниципаль район башлыгының “Мамадыш муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында” 2016 ел, 10 ноябрь, 112 нче санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Татарстан республикасы Мамадыш муниципаль районында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турындагы нигезләмәнең ( кушымта №1) 24 пунктының “в” подпунктын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

“халыкны гадәттән тыш хәлләр, аларның параметры һәм күләме, зарарлаучы факторлар, гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан зонада халыкны һәм территорияне тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар, саклану алымнары, гамәлләр тәртибе, гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан территориядә зыян күрүчеләрне хокукый һәм социаль яктан яклау чаралары, шул исәптән Россия Федерациясе законнары тарафыннан каралган түләүләр, гадәттән тыш хәлләр вакытында югалган документларны яңадан торгызу турында мәгълүмат белән таныштыру”.

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе И.М. Дәрҗемановка йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.П.Иванов

000107